РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«27» июня 2025 ел г. Альметьевск № 1542

**Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Физик культура, спорт һәм туризм идарәсенә гамәлгә куючының аерым функцияләрен һәм вәкаләтләрен тапшыру турында» 2022 елның 18 июлендәге 1490 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2006 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт (муниципаль) учреждениеләренең хокукый хәлен камилләштерүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»2010 елның 08 маендагы 83-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Физик культура, спорт һәм туризм идарәсенә гамәлгә куючының аерым функцияләрен һәм вәкаләтләрен тапшыру турында» 2022 елның 18 июлендәге 1490 номерлы карарына карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 3 июлендәге 2052 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карар исемендә һәм карарның 1 пунктында «Әлмәт муниципаль районының физик культура, спорт һәм туризм идарәсенә» сүзләрен «Әлмәт муниципаль районының физик культура һәм спорт идарәсенә» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«- муниципаль задание үтәлешен финанс белән тәэмин итүгә субсидия бирү турында килешүләр төзү;

- башка максатларга субсидияләр бирүгә килешүләр төзү, субсидияләр алучыларның субсидияләр бирү шартларын һәм тәртибен үтәвен тикшереп торуны гамәлгә ашыру, шул исәптән субсидияләр бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә.»;

карарга 1 нче кушымтаның 11 нче юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| 11 | «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Физик культура һәм спорт идарәсенең үзәкләштерелгән бухгалтериясе»муниципаль бюджет учреждениесе («ТР ӘМР ФКСИ ҮБ» МБУ) |

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында PRAVO.TATARSTAN.RU урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптевага йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе Г.М. Хәбутдинова